ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КРЫНДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЫРЫНДЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**26.03.2026** **Кырынды авылы** **№ 6**

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге территориясендә киселә торган яшел утыртмаларның бәясен исәпләү һәм компенсация яшелләндерү методикасын раслау турында» 20.08.2025 елның 9 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында

«Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге территориясендә киселә торган яшел утыртмаларның бәясен исәпләү һәм компенсация яшелләндерү методикасын раслау турында» 20.08.2025 елның 9 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.3 пунктының 4 абзацын төшереп калдырырга;

2) 1.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Яшел утыртмаларга хокуксыз зыян китергәндә яисә юкка чыгарганда зыянны исәпләү Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

3) 3.2 пунктының 2 абзацын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлегенең мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль
районының Кырынды авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р. Мәүликәев